| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«27» февраль 2026 ел № 223

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында һәм ясалма корылмаларда (күперләрдә) юл хуҗалыгы объектлары исемлеген раслау турында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында һәм ясалма корылмаларда (күперләрдә) юл хуҗалыгы объектларын исәпкә алу һәм инвентарьлаштыруны алып бару буенча комиссия төзү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2023 номерлы 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 декабрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында һәм ясалма корылмаларда (күперләрдә) юл хуҗалыгы объектлары исемлеген (1 нче кушымта) расларга.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында һәм ясалма корылмаларда (күперләрдә) юл хуҗалыгы объектларын исәпкә алуны һәм инвентарьлаштыруны алып бару комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта);
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин